**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «О реализации Федерального закона «Об организации регулярных перевозок пассажиров и багажа автомобильным транспортом и городским наземным электрическим транспортом в Российской Федерации и о внесении изменений в отдельные законодательные акты Российской Федерации»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
11 июля 2017 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 26 декабря 2015 года № 107-ЗРТ «О реализации Федерального закона «Об организации регулярных перевозок пассажиров и багажа автомобильным транспортом и городским наземным электрическим транспортом в Российской Федерации и о внесении изменений в отдельные законодательные акты Российской Федерации» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2015, № 12 (I часть); 2016, № 7 – 8) следующие изменения:

1) часть 1 статьи 3 дополнить пунктом $3^1$ следующего содержания:
«$3^1$) устанавливает требования к осуществлению перевозок по межмуниципальным маршрутам регулярных перевозок по нерегулируемым тарифам;»;

2) статью 4 дополнить пунктом $7^1$ следующего содержания:
«$7^1$) устанавливают при необходимости требования к осуществлению перевозок по муниципальным маршрутам регулярных перевозок по нерегулируемым тарифам;»;

3) в части 6 статьи 7:

а) в пункте 1 слова «, а в случае осуществления перевозок по межрегиональным маршрутам регулярных перевозок, установленным уполномоченным федеральным органом исполнительной власти, невыполнение более пяти рейсов подряд» исключить;

б) пункт 5 признать утратившим силу;

в) дополнить пунктом 6 следующего содержания:

«6) повторное в течение одного года нарушение требований к осуществлению перевозок по нерегулируемым тарифам, установленных нормативным правовым актом Кабинета Министров Республики Татарстан, муниципальным нормативным правовым актом в случае установления указанных требований органом местного самоуправления.».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ *
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
20 июля 2017 года
№ 59-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” Федераль законны гамәлгә ашыру турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 11 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

“Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” Федераль законны гамәлгә ашыру турында” 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы җыелма басмасы, 2015, № 12 (I өлеш); 2016, № 7 – 8) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле $3^1$ пункт өстәргә:
“$3^1$) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутларында җайга салынмый торган тарифлар буенча пассажирлар йөртүгә һәм багаж ташуга таләпләр билгели;”;

2) 4 статьяга түбәндәге эчтәлекле $7^1$ пункт өстәргә:
“$7^1$) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутларында җайга салынмый торган тарифлар буенча пассажирлар йөртүгә һәм багаж ташуга таләпләр билгели;”;

3) 7 статьяның 6 өлешендә:
а) 1 пунктта “, ә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы билгеләгән даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм

багаж ташуның регионара маршрутлары буенча гамәлгә ашырылган очракта, рәттән кимендә биш рейс үтәлмәсә" сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 5 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

в) түбәндәге эчтәлекле 6 пункт өстәргә:

«6) җирле үзидарә органы тарафыннан билгеләнгән очракта – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты норматив хокукый акты белән, муниципаль норматив хокукый акт белән билгеләнгән җайга салынмый торган тарифлар буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга таләпләрне бер ел эчендә кабат бозган очракта.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан,Кремль
2017 ел, 20 июль
№ 59-ТРЗ